# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**17.12.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 17 декабрендә 09:00 һәм 17:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ироектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Иж-Бубый авылында су белән тәэмин итүгә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, Иж-Бубый авылында суүткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- Иж-Бубый авылында авыл эчендәге юлларга вак таш җәю
- Иж-Бубый урамнарын кардан чистарту
- Иж-Бубый авылында авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү
- ДТ-75 тракторын ремонтлау һәм карап тоту
- Балалар мәйданчыгы өчен уен корылмалары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 492 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 258 кеше, бу 52,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 247 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 11 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

– Иж-Бубый авылында су белән тәэмин итүгә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, Иж-Бубый авылында сусүткәргеч челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
– Иж-Бубый авылында авыл эчендәге юлларга вак таш җәю
– Иж-Бубый урамнарын кардан чистарту
– Иж-Бубый авылында авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү
– ДТ-75 тракторын ремонтлау һәм карап тоту

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. ВАҺАПОВ

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения
Иж-Бубый авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002460
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ